**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**11 ноябрь 2025 ел** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципалары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында" 27.10.2025 ел № 4 карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

-урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар өчен мәйданчыкларны, бүлү нокталарын һәм электр тоташуларын һәм электр энергиясен тапшыруны тәэмин итү өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергияне саклаучы лампалар, электр товарлары, махсус җиһазлар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту җайланмаларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктыртуларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү );

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Яшьләр, Бакча, Яналиф урамнары буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, җәю);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62 нче йорт; Тельман ур., 75 нче йорт адреслары буенча Тымытык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Мостафина